Семантик калькалар чит тел сүзенең мәгънәсен күчерү нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Рус сүзләренең аерым мәгънәләрен үзләштерү нәтиҗәсендә туган калькалар татар телендә күп. Шулар арасыннан географик атамаларны (борын, култык, бугаз), оешмалар җыелмасын (челтәр), иҗтимагый төркемнәрне (уң, сул) һәм терминнарны (көрәш, күчеш, нигез, сайлау, җыелыш, агым) белдерүче калькалар очрый. Вакытлы матбугатта бу төргә караган мисаллар аз. Казанда уздырылган шәһәр наркотикларга каршы көрәш комиссиясе утырышынды Республика *нарколог* (наркология дип әйтү уңышлырак) диспансерының баш табиб урынбасары Степан Криницкий билгеләп үткәнчә〈...〉 [«Шәһри Казан», 2013: 7] җөмләсе калькалар ягыннан гына түгел, сөйләм төзеклеге буенча да аңлаешсыз бирелгән.

Кызганыч, бүген телебездә – халыкның сөйләм телендә дә, әдәби телебездә дә – төрле характердагы төгәлсезлекләр, әдәби тел нормаларын бозулар күзәтелә. Телнең дөреслеген, сафлыгын сакларга тиешле кешеләр – тел белгечләре, журналистлар, укытучылар тарафыннан да бу мәсьәләгә игътибар җитеп бетми, фәнни хезмәтләрдә, вакытлы матбугат битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында сөйләм культурасына бәйле проблемалар аз күтәрелә.

Татар һәм рус телләренең дәүләт теле буларак тигез хокуклы статусы игълан ителүгә карамастан, татар телендә эшләү чикләнгән килеш кала бирә. Бөек шәхесебез Ризаэтдин Фәхреддин әйткәнчә, һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык һәр һөнәр, һәм дә сәнәгать өлкәләрендә милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиешләр. Бу фикер бүген дә көчендә кала.

**Литература**

1. Юсупов, Р.А. Әдәп башы – тел. Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре / Р. А. Юсупов. – Казан: КДПУ нәшрияты, 2000. – 218 б.

2. Сафиуллина, Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. Югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Тарих, 2001. – 383 б.

***Габдрахманова Фәнүзә Хәйдаровна***
Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## ТАТАР ЛИНГВОМӘДӘНИЯТЕНДӘ *БУСАГА* ЛЕКСЕМАСЫНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ-СЕМАНТИК КЫРЫ

*В статье приведен пример лингвокультурологического анализа лексемы бусага (порог) в татарской языковой картине мира, относящейся к материальной культуре татарского народа.*

**Ключевые слова:** *татарская лингвокультура, лексема, функционально-семантическое поле, лингвокультурологический анализ.*

*The article is about a linguacultural analys of lexeme busaga (threshold) which refers to the material culture of the Tatar people.*

**Key words:** *tatar linguacultura, lexeme, functional-semantic field, linguacultural analys.*

Бүгенге татар тел белемендә яңа юнәлеш – тел берәмлекләрен үзенчәлекле күзлектән чыгып, мәдәният, менталитет, дөньяга караш аша анализлап өйрәнү формалашып килә.

Яңа юнәлеш булуына карамастан, соңгы берничә ел эчендә генә дә лингвокультурологик аспектта аерым халыкларның милли тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган күпсанлы хезмәтләр белән танышырга мөмкин. Шул исәптән татар телендә дә шактый хезмәтләрне санап чыга алабыз. Мәсәлән, Р.Р. Җамалетдинов, Э.М. Җиһангирова, Э.Н. Гыйләҗева, Ә.Ш. Василова, Л.Х. Шәяхмәтова, Л.Р. Гарипова, Д.Х. Хөснетдинов һ. б.

Лингвокультурология термины, сүзеннән үк аңлашылганча, «лингвистика» һәм «культурология» берәмлекләреннән тора. Соңгы елларда тел белеме фәненең башка өлкәләр белән чиктәшлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән юнәлешләр моннан башка да бар. Мәсәлән, психолингвистика, лингводидактика, лингвистик география һ. б. Димәк, лингвокультурология ике фән чигендә барлыкка килеп, халык мәдәниятенең телдә чагылышын, язуда, аңда сакланып калуын өйрәнә. Тел ул халыкның милләт булуын саклый торган күрсәткечләрнең берсе, ул шулай ук халыкның мәдәниятен яшәтү, үстерү һәм интерпретацияләү чарасы булып та тора.

Чыннан да, тел тормыш-чынбарлыкны чагылдырып кына калмый, ә кеше яши торган реаль эчке дөньяны интерпритацияли. Шуңа да тел белеме халыкның мәдәниятен өйрәнүдә эчтәлекле чыганак хезмәтен үти. Гасырлар дәвамында үзгәрмичә, халык сөйләмендә кулланылып килгән берәмлекләрне өйрәнеп, шул телдә сөйләшүче халыкның менталитетын, фикер сөрешен, әйләнә-тирә дөньяга мөнәсәбәтен ачыкларга мөмкин.

Туган тел һәр халыкның, һәрбер милләтнең тарихи үткәне, бүгенге яшәеше һәм киләчәк язмышы өчен гаять әһәмиятле факторларның берсе. Телдәге һәр күренешне өйрәнү, аның асылына төшенү бу халыкның туган теле, тел һәм мәдәнияте арасындагы бәйләнеш дәрәҗәсен билгеләүдә дә мөһим роль уйный. Рухи һәм матди мәдәният лексикасы да, бу нисбәттән, аерым игътибарга лаек. Чөнки аларда халыкның көнкүреше, менталитеты, дине, гореф-гадәтләре белән бәйле күп кенә иҗтимагый, мәдәни, психологик мәгълүмат саклана. Материаль лексикага караган сүзләр теләсә кайсы мәдәният, теләсә нинди тел лексикасы өчен әһәмиятле. Материаль лексика сүзлек запасыбызның өзлексез хәрәкәттә булган өлешен алып тора, көндәлек тормышта, хуҗалык алып барганда яшәеш өчен кирәкле булган барлык

төшенчәләр, предмет атамалары әлеге лексикага карый. Без, үз чиратында, матди мәдәният лексикасының «йорт-торак» семантик төркеменә караган *бусага* лексемасы белән кызыксынып, аны лингвокультурологик аспектта тикшерергә алындык.

*Бусага* – ишек белән турыдан-туры бәйләнгән лексема. Иң беренче сүзнең килеп чыгышына игътибар итик, чөнки этимологияне карау сүзнең ни дәрәҗәдә борынгылыгын, бүгенге телдә кулланыла торган башка лексик берәмлекләр белән бәйләнешләрне барлау өчен мөһим Гомумтөрки *босага* сүзе монгол теленнән алынган дип исәпләнелә. Сүз составында монгол-төрки морфологик элементлар бар шикелле тоелса да, сүзнең ясалышы һәм тамыры ачык түгел [Әхмәтьянов, 2001: 54]. Аның туры мәгънәсе бу сүзнең рус телендәге мәгънәсе белән туры килә – ишекнең яткырып салынган аскы борысы, төбе [Татар, 2005: 98].

Ишек вазифасы – керү һәм чыгуны тәэмин итү. Ә чик *бусага* аша үтә.

Ә. Еники иҗатында *бусага* лексемасының беренчел номинацияләү очракларын күрә алабыз: *Шул арада ишек бусагасында Зәйнәп күренде. Ул бер генә секундка тукталды һәм өй эчен яңгыратып:*

*– Абый! – дип бер кычкырды да яшен тизлеге белән ишектән кире тышка атылды (“Бер генә сәгатькә”).*

*Бусага*ның башлангыч чор, яки нәрсәнең дә булса алды дигән күчерелмә мәгънәсе дә бар. Мәсәлән, М. Әгъләмовның «Акмулла арбасы» поэмасында *бусага* лексемасы *башлангыч чор* мәгънәсендә кулланыла:

*Ә без менә гәҗит битләрендә*
*Урын алган купшы җырларда*
*Егерменче гасыр бусагасын*
*Таптап төшерергә торганда,*
*Бүлмәләргә кереп бикләнгәнбез,*
*Ишекләргә тишек тишкәнбез...*
*Китапларны ачып салганбыз да*
*Белем коесына төшкәнбез.*

Шагыйрьнең «Туй» шигырендә *бусага, тупса яңа тормышка аяк басу* буларак та аңлашыла:

*Изге юллар өчен пар канатлар,*
*Пар канатлар оча – пар атлар...*
*Пар атлардан төшеп мендәргә бас,*
*Бусагага кадәр паласлар.*
*Атлап керсәң өйнең тупсасыннан,*
*Карап тора сиңа мең чигеш;*
*Әйтерсең лә Урал тавы аша*
*Көнбатышка карый Көнчыгыш.*

*Бусага* лексемасы өй, туган йорт, туган җир мәгънәсендә дә кулланылырга мөмкин: *Үз бусагаңнан чыгып киттеңме, туган җиреңне аңлый башлыйсың, ныграк сагынасың, диләр (А. Гыйләҗев).*

Х. Туфанның «Митта-а!» шигырендә *бусага* сүзе *урын* мәгънәсендә кулланыла:

*Еракмыни Казан Шупашкардан...*
*Янәшә дә безнең бусага,*
*Күрешмәдек, энем, тормышта без*
*Узган юллар бер үк булса да.*

Телебездә, бигрәк тә кайбер диалектларда бусаганың синонимы буларак *тупса* сүзе кулланыла: *Ишек артында гына көтеп торган кебек, кинәт тупсада Ак бабай пәйда булды (Г. Гыйльманов).*

«Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә *бусага* лексемасының түбәндәге мәгънәләре бирелә: 1. а) чистай сөйләшендә – ишек төбе; б) әстерхан сөйләшендә – өй алды. 2. Ләмбрә сөйләшендә – яшь киленнең беренче кергәндә бирә торган бүләге [Татар, 2009: 139].

Татар телендә *бусага* компоненты кергән фразеологизмнар шактый: *бусага атлау* – керешү, башлап җибәрү; *бусага таптау* – үтенеч белән күп тапкырлар килү; *бусагага бару (килү, егылу)* – кеше каршысына, йортына гозер, йомыш, үтенеч белән ялварып килү. Санап үтелгән фразеологизмнарда татар менталитеты вәкиленә *бусага* кем каршынадыр үтенеч белән бару зарурлыгы кебек аңлашыла. *Бусагага аяк басмау, бусагадан аяк атлатмау* – каядыр булса бүтән килмәү, китермәү; өйгә кертмәслек начар; *бусагадан гәүдә аша чыгу* – нинди дә булса эшне шул эшне башкарырга рөхсәт итмәгән кеше үлгәч кенә эшләү.

*Күңел бусагасы* – кеше күңеленең түре, чаты: *Дәшәм дисә дә дәшә алмас иде, мөгаен, аның бөтен шатлык-куанычы күңел бусагасына килеп төялгән дә, элгәре җыелып каткан сагыш кантарларын куптара алмый газаплана иде бу минутта (Г. Гыйльманов).*

Бусага сокраль мәгънәгә дә ия. Татар халкында *бусагага утырырга ярамый, бусага аша акча бирергә ярамый* дигән ышанулар яши. Борынгылар фикеренчә, ишек төбендә җен-шайтаннар яши, шуңа күрә бусагага утырырга ярамый һәм бусага аша бирелгән акча бәрәкәтле булмый дип фараз итәргә була. Димәк, татар халкы шулай зирәк рәвештә этикет кагыйдәләренә өйрәтә.

Шулай итеп, татар телендә *бусага* лексемасының функциональ-семантик кыры киң һәм ул:

ишекнең яткырып салынган аскы борысы, төбе;
урын;
яңа тормышка аяк басу;
башлангыч чор
мәгънәләрен ала һәм сокраль мәгънәгә ия дип әйтә алабыз.

**Әдәбият**

Әхмәтьянов, Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Җамалетдинов, Р.Р. Татар теленең этнокультура лексикасы: сүзлек-белешмәлек / Р.Р. Җамалетдинов. – Казан: Алма-Лит, 2003. – 144 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге // төз. Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

***Габдуллина Алсу Зөфәровна***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## КАЗАН ШӘҺӘРЕ ЭРГОНИМНАРЫНЫҢ УКУЧЫЛАР АҢЫНА ТӘЭСИРЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Данная статья посвящена анализу влияния эргонимов г. Казани на сознание современного школьника. В работе обозначен основной генетический пласт эргонимии г. Казани и показано место эргонимов в системе ономастических единиц, как эффективных средств рекламы. В ходе исследования, с целью выявления особенностей восприятия окружающего мира учениками, был проведен ассоциативный эксперимент.По итогам эксперимента выявлены влияние национального подсознания на мышление школьника, а также положительная оценка и легкое восприятие мотивированныхэргонимов*.

**Ключевые слова:** *эргоним, мотивированный эргоним, языковая личность, ономастическая единица, восприятие и оценка, национальное подсознание, ассоциативный эксперимент*.

*This article analyzes the influence of Kazan ergonims on the consciousness of the modern schoolchild. The paper outlined the main genetic layer of Kazan er-gonemy and shows the location of the ergonims in the system of onomastic units as an effective means of advertising. In a study to identify the features of perception of the world by pupils an associative experiment has been conducted. According to the results of the experiment the impact of the national subconscious on schoolchild thinking and a positive assessment of the light perception of motivated ergonims have been revealed.*

**Key words:** *ergonim, motivated ergonim, language personality, onomastics unit, perception and evaluation, national subconscious, associative experiment*

Теге яки бу товар маркасы, яисә кибет, оешма, һ.б. предприятиеләрнең атамасы җитештерелә торган товар белән потенциаль сатып алучы